МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

06.06.2016 г. Казань № под-1115/16

**«Татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмгә үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында типовой нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 17 ноябрендәге 862 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет утырышы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта «18 кеше» дигән сүзләрне «12 кеше» дигән сүзләргә алыштырырга;

3.3. пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән затлар, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән бер өлешеннән артмаган санда, керергә мөмкин».

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Б.Алишевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.ФӘТТАХОВ